ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.10.2024 г.Казань № 303-12/т-2024

Әлмәт шәһәренең «Промтранс-А» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланудa булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә 2025 елга чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бәяләрне (тарифларны) дәүләт тарафыннан җайга салуны тәртипкә китерү чаралары турында» 1995 елның 7 мартындагы 239 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсе утырышының 31.10.2024 ел, № 23-ПР беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт шәһәренең «Промтранс-А» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан гомуми файдаланудa булмаган тимер юлларда күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә шушы карар кушымтасына туры китереп, чик дәрәҗә максималь тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән иң чик максималь тарифлар 2025 елның 1 гыйнварыннан 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
31.10.2024 № 303-12/т-2024
карарына кушымта

Әлмәт шәһәренең «Промтранс-А» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте тарафыннан керү тимер юлларында күрсәтелә торган транспорт хезмәтләренә иң чик максималь тарифлар

I бүлек. Иң чик максималь тариф

| Т/с | Хезмәт төре | Үлчәү берәмлеге | Чик дәрәҗәдә максималь тариф, сумнарда (өстәмә хак салымын исәпкә алмыйча) |
|---|---|---|---|
| 1. | Әлмәт маневр районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 28,85 |
| 2. | Түбән Кама маневр районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 21,23 |
| 3. | Түбән Кама нефть базасы кишәрлеге буенча 1 км ераклыкка йөк ташу | 1 тонна | 3,60 |
| 4. | Алан (Алан ст.) маневр районы буенча 1 км ераклык өчен йөк ташу | 1 тонна | 60,91 |

II бүлек. Башка шартлар

1. Сәнәгать тимер юл транспорты предприятиесе тарафыннан башкарыла торган, әмма «Чик дәрәҗәдә максималь тариф» I бүлектә каралмаган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар яклар килешүендә, Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 2001 елның 20 декабрендәге АН-104-р номерлы күрсәтмәсе белән расланган Сәнәгать тимер юл транспортында башкарыла торган эшләргә һәм хезмәтләр күрсәтүгә тарифлар һәм җыемнар формалаштыру буенча методик күрсәтмәләр нигезендә билгеләнә.

2. Йөк ташу һәм төяп җибәрү-бушату эшләре өчен түләү заказчыдан ташылган йөкнең фактик авырлыгы өчен алына.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының тариф карарларын кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге